ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
V чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
V созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

КАРАР
04.03.2026г

РЕШЕНИЕ
№06-05

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 12-15 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр керту турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнары, "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Актаныш муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 12-15 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторларының вәкаләтләре чоры 5 ел тәшкил итә".

1.2. 6 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары һәм аудиторлары вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары һәм аудиторлары «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне тапшырырга тиеш. Әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов